**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**

**Бохарай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№107** **24 сентябрь 2018 ел**

**Бохарай авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Бохарай авыл җирлеге Уставы, «Референдум уздыруны башлап йөрү турында» 2018 елның 24 сентябрендәге 18 номерлы Бохарай авыл җирлеге башкарма комитеты карары, «Референдум уздыруны башлап йөрү турында» 2018 елның 24 сентябрендәге 106 номерлы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Бохарай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Утвердить вопрос, выносимый на местный референдум:

«2019 елда тавыш бирү көненә 18 яше тулган яшәү урыны Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге чикләрендә урнашкан авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, елга бер мәртәбә 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасы түләүне кертү, җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Бохарай авылы: Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерү (сәхнә ясау); чишмәне төзекләндерү (беседка сатып алу һәм урнаштыру);
- Алкин авылы: торак пункт эчендә юлга комлы-таш җәю; агачларны кисү;
- Шунак авылы: елга аша чыгу өчен күперчек төзү;
- Сармаш-Ирнә авылы: торак пункт эчендә юлга комлы-таш җәю.

ӘЙЕ ЮК».

3. Карарны кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Совет рәисе** **Р.И.Нуриев**